БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 5 » май 2018 ел № 140

"Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутлар реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибен, муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртү хокукына ачык конкурста катнашуга гаризалар критерийларын бәяләү өчен шкаланы раслау турында" 2016 елның 30 сентябрендәге 213 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 декабрендәге 480-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутлар реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибен, муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртү хокукына ачык конкурста катнашуга гаризалар критерийларын бәяләү өчен шкаланы раслау турында" 2016 елның 30 сентябрендәге 213 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 2.1.1 пунктын өстәргә:

"2.1.1. Элек билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү муниципаль маршрутлы, ике һәм аннан да күбрәк гомуми тукталыш пункты булган даими рәвештә пассажирлар йөртү муниципаль маршрутын билгеләү яисә үзгәртү әлеге маршрутларны билгеләү аларның компетенцияләренә кертелгән

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы белән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты арасында килештереп гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән килештерү тәртибе Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акты белән билгеләнә."

1.2. 3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.4. Әгәр даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы белән килештерелмәгән булса, мондый таныклыкның гамәлдә булу вакыты дәвамында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты инициативасы буенча тиешле маршрутны үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында карар мондый таныклыкның гамәлдә булу вакыты тәмамланган көнгә кадәр йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый таныклыкның гамәлдә булу вакыты тәмамланган көннән үз көченә керә."

1.3. түбәндәге эчтәлекле 3.5 пункт өстәргә:

"3.5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын үзгәртү турында әлеге тәртипнең 3.4 пунктында каралган карар кабул иткән көннән алып алтмыш көн эчендә, әлеге маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыклар бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар, гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына, кабул ителгән карар нигезендә, әлеге маршрутларның мондый таныклыкларының һәм карталарының гамәлдә булуын киләсе срокка озайту турында гаризалар белән мөрәҗәгать итәргә тиеш."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Р. И. Шакиров